**МЕЖРЕГИОНАЛЬНАЯ ОЛИМПИАДА ШКОЛЬНИКОВ «ЮНИОР»**
**ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ**
**ЗАКЛЮЧИТЕЛЬНЫЙ ЭТАП**
**2023-2024 учебный год**
**6 КЛАСС**

**Таблица ответов**

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| а | | | | **X** | | | | | | | | **X** | | | | | | | | |
| ә | **X** | **X** | | | | | **X** | | | | | | | | | **X** | | | **X** | |
| б | | | **X** | | | | | | **X** | **X** | | | **X** | **X** | | | | | | **X** |
| в | | | | | **X** | **X** | | **X** | | | **X** | | | | **X** | | **X** | **X** | | |
| | *задания по 1 баллу* | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

1. Кайсы аваз яңгырау? (1 балл)
а)[һ];
**ә)[й];**
б)[т];
в)[с].

2.Кайсы сүзлектә сүзнең төп һәм өстәмә мәгънәләре күрсәтелә? (1 балл)
а) татарча-русча сүзлек;
**ә) аңлатмалы сүзлек;**
б) диалектологик сүзлек;
в) орфоэпик сүзлек.

3. Авазлар саны белән хәрефләр саны туры килгән сүзләр рәтен билгеләгез. (1 балл)
а) сәгать, дәреслек, яшел;
ә) югары, елга, ялкын;
**б) дөнья, берьяклы, ямьле;**
в) хикәя, боеру, юлдаш.

4. Су хәрәкәт итә һәм үзенең **<u>этрафындагы</u>** бөтен нәрсәләргә тереклек бирә (Г. Тукай) җөмләсендәге **<u>этраф</u>** сүзе –(1 балл)
**а) диалекталь сүз;**
ә) архаизм;
б) неологизм;
в) тарихи сүз.

5. Ясалма сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. (1 балл)
а) яшел, төркем, тамыр;
ә) җирдәге, торак, үзгәреш;
б) замана, тәрәзә, мәктәп;
**в) дәрестә, нигезне, шәһәргә.**

6. Фразеологик әйтелмә булмаган рәтне билгеләгез. (1 балл)
а) бармак белән төртеп күрсәтү;
ә) бармак белән санарлык;
б) бармак белән дә чиртмәү;
**в) бармакка бармак та сукмау.**

7. Неологизмнар дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (1 балл)
а) китап, сәгать, көй;
**ә) флешмоб, тренд, коллаж;**
б) калфак, патша, курай;
в) гыйлем, еглау, мәктүп.

8. Парлы сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (1 балл)
а) кара(бодай), баш(кала);
ә) каен(җиләге), бака(яфрагы);
б) бал(корты), чәй(эчү);
**в) көн(төн), ата(ана).**

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән исемнең килеше дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (1 балл)
Йомырка **<u>тавыкны</u>** өйрәтми. (Мәкаль)
а) баш килеш;
ә) юнәлеш килеше;
**б) төшем килеше;**
в) чыгыш килеше.

10. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сыйфатның дәрәҗәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (1 балл)
Бөтен тирә-як **<u>ап-ак</u>** юрган астында калган кебек иде. (Шәриф Биккол)
а) гади;
ә) чагыштыру;
**б) артыклык;**
в) кимлек.

11. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән санның төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (1 балл)
Бер гектар карабодайдан умарта кортлары **<u>60-90</u>** килограммга кадәр бал җыялар. (1 балл)
а) микъдар;
ә) бүлем;
б) җыю;
**в) чама.**

12. Җөмләнең иясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (1 балл)
Сүз чыпчык булып авыздан очып чыга да кире әйләнеп кайтмый. (Лена Шагыйрьҗан) (1 балл)
**а) сүз;**
ә) чыпчык;
б) авыздан;
в) очып чыга

13. Кайсы сүз тамыр, ясагыч һәм бәйләгеч кушымчалардан тора?
а) урамдагы;
ә) әнкәйне;
**б) юлдашка;**
в) кызчыктан.

14. Исем нәрсәне белдерә? (1 балл)
а) предметның төсен белдерә;
ә) предметның эш-хәрәкәтен белдерә;
**б) предметны белдерә;**
в) предметның исәбен белдерә.

15. Тиеннәр ямь-яшел чыршы ботагында утыра, ап-ак кар белән капланган ботакларда тирбәлешә (Г. Хәсәнов) җөмләсендәге сыйфатларның дәрәҗәсен билгеләгез.
а) гади;
ә) чагыштыру;
б) кимлек;
**в) артыклык.**

16. Җөмләнең кайсы кисәкләре тиңдәшләнеп килә алмый?
а) баш кисәкләр;
**ә) баш һәм иярчен кисәкләр;**
б) иярчен кисәкләр;
в) аергычлар.

17. Шигырьнең авторы кем? (1 балл)
“Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным, тәнем белән.”
а)М.Гафури
ә)Дәрдемәнд
б)М.Җәлил
**в)Г. Тукай**

18.Муса Җәлилнең туган авылы: (1 балл)
а)Кушлавыч
ә)Казан
б)Кырлай
**в)Мостафа**

19. Шигырьдә төшеп калган сүзне күрсәтегез. (1 балл)
“ ________________таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.
Менә — балам. Син әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм.” (Ф.Кәрим)
а)фашистлар
**ә)юлбасарлар**
б)алпавытлар
в)дошманнар

20. Бирелгән өзек кайсы әсәрдән? (1 балл)
“Барлык бүлмәләрдә йөреп чыккач, егетләр укырга утырдылар. Ләкин бер-берсенең нәрсә укуы турында сорашмаска сүз куештылар. Кайбер әйберләрне язып алырга да кирәк иде. Ләкин болай эшләсәләр, мәгарәдән чыкканда, язган кәгазьләрен алып калулары мөмкин. Шуңа күрә алар үзләре белән суган суы алып кергәннәр иде, шуның белән бик кирәкле белемнәрне язгалап та алдылар. “
а) Сибгат Хәким “Бакчачылар”
ә) Гадел Кутуй “Сагыну”
**б) Каюм Насыйри “Әбугалисина”**
в) Галимҗан Ибраһимов “Алмачуар”

II. Башыгызны эшләтегез.

Кушма исемнәр килеп чыгарлык итеп, шакмакларга хәрефләр языгыз. ъ хәрефе бу очракта аеру билгесе булып тора. (10 балл)

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ъ | | | | | | |
| | | ъ | | | | | | |
| | | ъ | | | | | | |
| | | ъ | | | | | | |
| | | | ъ | | | | | |
| | | | ъ | | | | | |
| | | | ъ | | | | | |
| | | | ъ | | | | | |

**III.Иҗади бирем.**

Кыш көннәрен сурәтләп, кечкенә генә сочинение төзеп языгыз. (10 җөмлә).

Иҗади биремне бәяләү критерийлары:

1. Язма эшнең эчтәлеге темага туры килә – 2 балл

Язма эшнең стуктур элементлары (кереш өлеше, төп өлеше, нәтиҗә) төгәл күрсәтелгән - 3 балл

2. Орфографик хаталар 1-2 күп түгел- 2 балл
3. Пунктуацион хаталар 1-2 күп түгел – 1 балл
4. Логик хаталар юк- 1 балл
5. Фактик хаталар юк – 1 балл